КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 декабрь г.Казань № 1555

2024 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау турында

Психик бозылышлары булган инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационарны алыштыра торган технологияләрен үстерү, аларның тормыш сыйфатын яхшырту һәм аларны җәмгыятькә социаль интеграцияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2024 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны 1 көн белән 1 урын өчен 998,67 сум күләмендә;

2024 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүнең 1 сәгате өчен 52,56 сумга тигез күләмдә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләп чыгару тәртибе һәм 2023 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә

норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау турында» 2023 ел, 13 май, 592 нче карарының 1 пунктындагы өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин